**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Спас авыл җирлеге составына керүче Ефановка авылы торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**2022 елның 26 ноябре** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Спас авыл җирлегенең Ефановка авылында гражданнар җыены

Карар итте:

1. 2023нче елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Спас авыл җирлеге Ефановка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.
2. Җыелган акчаларны «Ефановка» стеласын реконструкцияләүгә; урамнар күрсәткечләрен, йортларның адреслы һәм номер табличкаларын әзерләүгә һәм урнаштыруга юнәлдерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Спас авыл җирлеге башлыгы** **А. С. Мухалев**